КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 31 июль г.Казань № 609

2025 елга Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Чираттагы елга Россия Федерациясе субъектларында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 26 июнендәге 1022 номерлы карары, «Татарстан Республикасында яшәү минимумы турында» 2005 елның 20 июлендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2025 елга Татарстан Республикасында яшәү минимумы күләмен халыкның җан башына исәпләгәндә – 15 073 сум, эшкә яраклы халык өчен – 16 430 сум, пенсионерлар өчен – 12 963 сум, балалар өчен 14 621 сум итеп расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин